# ФОТОРЕПОРТАЖ
## МБОУ «Школа №86»Советского района г.Казани

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ
И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
2021
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ
ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ



ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН 2021

# МБОУ «Школа №86»Советского райо...





## Тел-халыкның көзгесе

18-19 нчы февраль көнне Совет районының 86 нчы урта белем бирү мәктәбендә Туган телләр фестивале ачылуы уңаеннан 4-11 нче сыйныф укучылары тарафыннан оештырылган зур чара үткәрелде. Фестивальнең беренче көнендә мәктәп рекреацияләрендә кызыклы флешмоблар оештырылды. Ә актлар залында 1-11 сыйныф укучылары өчен Татарстанда яшәүче милләтләр, аларның гореф-гадәтләре, йолалары, милли киемнәре, ризыклары турында мәгълүмат бирделе. Шулай ук викторина сорауларына да урын табылды. Шул ук вакытта мәктәбебез спорт залында 2-4,5-7 сыйныфлар арасында милли уеннар оештырылуы бик мавыктыргыч булды. Фестивальнең беренче көн йомгагы булып укучыларның әти-әниләре перешереп алып килгән татлы ризыклардан авыз итү булды.

Фестивальнең икенче көнендә мәктәбебез укучылары үзләре әзерләгән концерт номерлары белән таң калдырдылар. Биредә рус, татар, инглиз телләреннән тыш, уйгур, казах, әзербәйҗан, калмык, грузин телләрендә җырлар, шигырьләр, сәхнәләштерелгән әкиятләр ишетелде.







